# КУШМА КАТНАШ ЭСТАФЕТАДА 4Х100 ДИСТАНЦИЯГӘ ЙӨЗҮ БУЕНЧА БӨЕКБРИТАНИЯ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ АЛТЫН МЕДАЛЬ АЛДЫ

05.08.2015, 19:34

СПОРТ

**Әлеге минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында бүгенге көннең соңгы финал йөзеше тәгәлләнде. 4х100 кушма микст эстафетада планетаның иң әйбәт 8 җыелма командалары ярышты.**

Британиялеләр иң көчлеләр булдылар - аларның күрсәткече 3:41.71. Әлеге күрсәткеч белән алтынны яулап кына калмадылар, ә дөнья рекордын да яңарттылар. Алар артыннан финишка Америка командасы килде, аларның күрсәткече - 3:43.27. Призлы өчлекне немец җыелма командасы япты, алар дистанцияне 3:44.13 күрсәткече белән үттеләр.

ДЧ-2015. Йөзү

4х100 кушма эстафета, микст.

1. Бөекбритания - 3:41.71

2. АКШ - 3:43.27

3. Германия - 3:44.13

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА